ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НАЛАСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Вахитова, д. 64, с.Наласа,
Арский муниципальный район, 422018

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НАЛАСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
М.Вахитов урамы, 64 йорт, Наласа авылы,
Арча муниципаль районы, 422018

Тел. (84366)50-2-25, факс (84366)50-2-25. E-mail: Nalas.Ars@tatar.ru

# КАРАР

« 01 » февраль 2022 ел № 2

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы « Наласа авыл җирлеге » муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияле хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 2022 елның 27 гыйнварындагы 57 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы « Наласа авыл җирлеге » муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияле хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләргә 1 нче һәм 2 нче кушымта нигезендә 6964 сум 68 тиен күләмендә бәя куярга һәм 2022 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Башкарма комитетының 02 февраль 2021 ел, №3 «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы « Наласа авыл җирлеге » муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияле хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында» карарын 2021 елның 1 февраленнән үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районы сайтында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам

Наласа авыл
җирлеге башлыгы: И.Р.Шакирова

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
аласа авыл җирлеге
башкарма комитетының
01.02.2022 ел, №2
карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Наласа авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияле хезмәтләрнең БӘЯСЕ**

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сум)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 4611,63 |
| 3. Мәрхүмнең мәетен (җәсәден) зиратка илтү | 556,94 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1796,11 |
| **Барлыгы** | **6964,68** |

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Наласа авыл җирлеге
башкарма комитетының
01.02 2022 ел, №2
карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Наласа авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияле хезмәтләрнең БӘЯСЕ**

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне тәрү | 250,61 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 4361,02 |
| 4. Мәрхүмнең мәетен (җәсәден) зиратка илтү | 556,94 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү ) | 1796,11 |
| **Барлыгы** | **6964,68** |